| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШЭhЭРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 25 «30» март 2022ел

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә халыкка мунча хезмәте күрсәтү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 8 номерлы Болгар шәһәр Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә халыкка мунча хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2.13 пунктында «кабул итүче тарафыннан аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 бүлегендә каралган» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Тәртипнең 4.2 пунктында «субсидияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын бозу фактлары» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган фактларны» сүзләренә алмаштырырга.

2. Субсидияләр алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: Комиссия секретаре Кузнецов Илһам Александровичны составтан чыгарырга, Комиссия секретаре составына Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Непомнющая Нина Николаевнаны кертергә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Спас муниципаль районы
Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Костина